КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 февраль г.Казань № 94

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсендәге су транспортында хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның кайбер категорияләренә социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында шәһәр яны элемтәсендәге су транспортында хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның кайбер категорияләренә социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2005 ел, 11 май, 209 нчы карарына (2005 ел, 17 ноябрь, 536 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче, 2021 ел, 20 май, 351 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

беренче абзацта «, Россия Федерациясе компетенциясенә керә торган социаль ярдәм чаралары» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорыннан тыш, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга йә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга;

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән яисә 2018 елның 31 декабренә торышы буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган хезмәт ветераннарына, 60 һәм 55 яшькә җиткәннән соң (тиешенчә ир-

атлар һәм хатын-кызлар) башка нигезләр буенча пенсия алучы яки эш (хезмәт) өчен гомерлек матди тәэминат алучы хезмәт ветераннарына;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, картлык буенча яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле стажы булган, пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән яисә 2018 елның 31 декабренә торышы буенча күрсәтелгән федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затларга, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 60 һәм 55 яшькә җиткәннән соң (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) пенсияләрне башка нигезләр буенча яисә эш (хезмәт) өчен гомерле матди тәэминат алучыларга.»;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта:

беренче абзацта «, Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торгансоциаль ярдәм чаралары» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, алар уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 18 яшькә җиткәнче (федераль дәүләт мәгариф оешмаларыннан тыш).»;

5 пунктның өченче абзацында «1, 2 һәм 3 пунктларда» сүзләрен «1 һәм 3 пунктларда» сүзләренә алмаштырырга;

6 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин